**Совет**
**Алешкин-Саплыкского**
**сельского поселения**
**Дрожжановского муниципального**
**района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Чүпрәле муниципаль районы**
**Алешкин-Саплык**
**авыл җирлеге**
**Советы**

**422478, Россия, Республика Татарстан, Дрожжановский район, с. Алешкин-Саплык, ул. Школьная, д.3а**
**тел. (84375) 37-5-35, 37-5-49, факс. 37-5-36**
**E-Mail:** AlSap.Drz@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Алешкин-Саплык

2020 нче елның 04 июне № 72/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2017 елның 29 декабрендә кабул ителгән 455-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплыкавыл җирлеге Советының 16.04.2012 ел, № 19/2 карары (30.11.2012 ел № 27/2, 15.10.2018 ел, № 44/2 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Алешкин-Саплык авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Ачык тыңлаулар халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге башлыгы, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Халык яки авыл җирлеге Советы инициативасы белән үткәрелә торган ачык тыңлаулар авыл җирлеге Советы, ә авыл җирлеге башлыгы яки авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән контракт

нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Алешкин-Саплык
авыл җирлеге башлыгы: П.Н.Артемьев